РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ**
**«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»**
**ЧИСТОПОЛЬСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ГЛАВА**
**ГОРОДА ЧИСТОПОЛЬ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

***Постановление*** ***Карар***

**25.02.2020 ел** **Чистай шәһәре** **№5**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башлыгының 2016 елның 21 мартындагы «Муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында»гы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. “Муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру” хакындагы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башлыгының 2016 елның 21 мартындагы 3 номерлы карарының 1 нче кушымтасы белән расланган муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль

районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов